Республика Татарстан

Глава Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05.07.2021 года

г. Менделеевск

№ 50

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре
Менделеевск муниципаль районы территориясендә
административ хокук бозулар турында
беркетмәләр төзү өчен
вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында» 18.11.2020 ел, № 91 карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru норматив документлар бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru урнаштырылга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Район башлыгы В.С.Чершинцев

КИҢӘШЛЕ:
ТР МК Аппараты җитәкчесе Р.Р.Искандаров

ТР ММР Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы Е.С.Царева

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Башлыгынын
2021 елның 5 июлендәге 50 номерлы карары буенча
кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә өстәмәләр

| ТР КоАП статьясы | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|
| 2.15 ст.2 өлеше. Террорчылыкны профилактикалау, минимальләштерү һәм (яки) аның нәтиҗәләрен бетерү буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яки бозу | Мобилизация эшләре буенча район башлыгы ярдәмчесе |
| Ст. 3.6. Авыл җирлекләре һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу | Менделеевск муниципаль районы Советының Мәгълүмати технологияләр белән тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Ст. 3.7. Этләрне урамда йөртү тәртибен бозу | Менделеевск муниципаль районы Советының Мәгълүмати технологияләр белән тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Ст. 3.10. (гражданнарга карата) Татарстан Республикасы территориясендәге су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу | Район башлыгының мобилизация эше буенча ярдәмчесе, район башлыгының коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесе, Менделеевск муниципаль районы Советының Мәгълүмати технологияләр белән тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Ст. 3.17. Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны урамда йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру | Менделеевск муниципаль районы Советының Мәгълүмати технологияләр белән тәэмин итү бүлеге башлыгы |